РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 24** **«23» мая 2019г.**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 23 апрелендәге 328 номерлы карарын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында»гы 2018 елның 22 августындагы 694 номерлы Карарын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон нигезендә»,

КАРАР БИРӘМ

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында»гы 2018 елның 22 августындагы 694 номерлы карарын тормышка ашыру чаралары планын (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, Чаралар планын җаваплы башкаручылар буларак, аның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. .Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына, «Мәгариф бүлеге» МКУ, район Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәгенә чаралар планын тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

4. Чаралар планын тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына һәр елны 25 гыйнварга кадәр район Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә аның үтәлеше турында мәгълүмат бирергә.

5. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И. В. Мөбиновка йөкләргә.

И.Ф. Зарипов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башлыгының
2019 елның 23 май 24 санлы
Карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында»гы 2018 елның 22 августындагы 694 номерлы Карарын тормышка ашыру буенча

ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

| № п/п | Чара исеме | Җаваплы башкаручылар | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Коррупциягә каршы тору турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүматның басма, электрон, челтәр чараларында пресс-релизлар җибәрү юлы белән тарату | Теләче районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары, «Мәгариф бүлеге» МКУ, район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәге (килешү буенча) | Квартал саен, 2030 елга кадәр |
| 2. | Теләче районында «Коррупциягә каршы тору сәясәтен тормышка ашыру» темасына интервьюлар һәм пресс-конференцияләр оештыру | Теләче районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары, район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәге (килешү буенча) | Ел саен 9 декабрьдә, 2030 елга кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан коррупциягә каршы тору буенча күрелә торган чаралар турында «Теләче» газетасына урнаштыру | Теләче районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары, «Мәгариф бүлеге» МКУ, район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәге (килешү буенча) | Квартал саен, 2030 елга кадәр |
| 4. | Теләче муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, район Советы аппараты җитәкчесе катнашында әлеге органнар эшчәнлегенең ачыклыгына ярдәм итү максатларында интервьюлар һәм пресс-конференцияләр оештыру һәм үткәрү | Район Башлыгы урынбасары, район Башкарма комитеты җитәкчесе, район Советы аппараты җитәкчесе, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәге (килешү буенча) | Ел саен 9 декабрьдә, 2030 елга кадәр |